**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 1** **30 ноябрь 2019 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге составына керүче Митрәй авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 30 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

« Сез, 2020 елда Әсәй авыл җирлеге Митрәй торак пункты территориясендә 1 Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 (Дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Митрәй авылында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергия саклаучы лампалар урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Митрәй авылы Тау асты, Тукай урамнары буенча вак таш (щебенка) җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Митрәй авылында юлларны кардан чистарту;
- Митрәй авылында җәйге чорда территорияне чабу;
- Митрәй авылында (зиарат, мәчет, мәдәният йорты территорияләрендә) коры агач, куаклар кисү, чабу;
- Митрәй авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);
- Митрәй авылында бәйрәм чараларын («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») оештыру һәм үткәрү;
- Митрәй авылында Бөек Ватан сугышы ветераннарына һәйкәле территориясенең чикләрен алмаштыру.

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 234 кеше теркәлгән, җыенда тавыш бирүдә катнашучылар саны - 164 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашучы 164 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар чыгарды:

1. Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге составына керүче Митрәй авылында узган халык җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: « Сез, 2020 елда Әсәй авыл җирлеге Митрәй торак пункты территориясендә 1 Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Митрәй авылында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергия саклаучы лампалар урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Митрәй авылы Тау асты, Тукай урамнары буенча вак таш (щебенка) җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Митрәй авылында юлларны кардан чистарту;
- Митрәй авылында җәйге чорда территорияне чабу;
- Митрәй авылында (зиарат, мәчет, мәдәният йорты территорияләрендә) коры агач, куаклар кисү, чабу;
- Митрәй авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);
- Митрәй авылында бәйрәм чараларын («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») оештыру һәм үткәрү;
- Митрәй авылында Бөек Ватан сугышы ветераннарына һәйкәле территориясенең чикләрен алмаштыру.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Митрәй авылы, Тукай ур.,15А йорт;

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әсәй авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әсәй авыл җирлеге Башлыгы — Идрисов З.Ә.